**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Яңа Нәдер авыл җирлеге аерым территориясендә хайваннар котыру авырулы булганга, аның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында**

Хайваннарның котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Әлеге Указның 2 пункты нигезендә билгеләнгән эпизоотия чыганагы һәм имин булмаган пункт территорияләрендә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертергә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:
а) эпизоотия чыганагын – «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Яңа Нәдер авыл җирлегендә Яңа Нәдер авылының Урман урамындагы 9 йортта урнашкан шәхси йорт хуҗалыгы территориясен;
б) имин булмаган пунктны – «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Яңа Нәдер авыл җирлеге Яңа Нәдер авылындагы эпизоотия чыганагы чикләреннән 2 км радиустагы территорияне.

3. Түбәндәгеләрне тыярга:
а) эпизоотия чыганагында:
котыру чиренә бирешүчән авыру хайваннарны дәвалауны;
җитештерү белән бәйле (технологик) операцияләрне, шул исәптән котыру чиренә бирешүчән хайваннарга хезмәт күрсәтүче персоналдан, эпизоотия чыганагын бетерүдә катнашучы дәүләт ветеринария хезмәте белгечләре һәм персоналдан, эпизоотия чыганагы территориясендә яшәүче һәм (яисә) вакытлыча торучы затлардан кала территориягә чит кешеләр керүен;
алып киткәнче 179 календарь көн дәвамында котыру чиренә каршы вакцина ясалган котыру чиренә бирешүчән хайваннарны, шул исәптән сугым предприятиеләренә яисә әлеге максатлар өчен җиһазландырылган сугым пунктларына иткә сую өчен алып китүдән тыш, котыру чиренә бирешүчән хайваннарны территориягә алып керүне (кертүне) һәм алып чыгуны (чыгаруны);

котыру чиренә бирешүчән хайваннарны күчереп йөртүне һәм төркемнәргә туплауны;

котыру чиренә бирешүчән хайваннар үләксәләренең тиреләрен салдыруны;

б) имин булмаган пунктта:

ярминкәләр, күргәзмәләр (сату итү) уздыру һәм котыру чиренә бирешүчән хайваннарны күчереп йөртү һәм туплау белән бәйле башка чаралар үткәрүне;

алып киткәнче 179 календарь көн дәвамында котыру чиренә каршы вакцина ясалган котыру чиренә бирешүчән хайваннарны, шул исәптән сугым предприятиеләренә яисә әлеге максатлар өчен җиһазландырылган сугым пунктларына иткә сую өчен алып китүдән тыш, котыру чиренә бирешүчән хайваннарны читкә чыгаруны;

котыру чиренә бирешүчән кыргый хайваннарны зоопаркларга чыгару өчен аулауны.

4. Карантин котыру чире белән авырый дигән шик тудыра торган котыру чиренә бирешүчән соңгы хайван суелган һәм (яисә) котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узгач, башка тиешле чаралар үтәлгәч бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 2 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә хайваннарның котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

7. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 09 февраль
№ ПУ-105